ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АГРЫЗСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул. Гагарина, д.13, г. Агрыз, 422230

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ӘГЕРҖЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Гагарин ур.,13, Әгерҗе шәһәре, 422230

Тел.: (85551) 2-22-46; Факс: 2-22-46; E-mail: isp.agryz@tatar.ru; www. agryz.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«26» май 2020 ел № 164

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы мәгариф учреждениеләрендә укучыларга коры паек бирү рәвешендә социаль ярдәмнең өстәмә чаралары турында

«Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Россия Федерациясе Законының 37 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәнең гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Россия Федерациясе Законының 16 статьясындагы 1 өлешенең 13 пункты, 20 статьясындагы 5 пункты, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2020 елга айлык акчалата һәм башка төр түләүләр турында» 2019 елның 28 августындагы 724 номерлы карары, «Татарстан Республикасының гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү территориаль өстәмә системасының идарә органнары һәм көчләре өчен югары әзерлек режимын кертү турында» 2020 елның 19 мартындагы 129 номерлы Татарстан Республикасы Президенты күрсәтмәсе нигезендә, Татарстан Республикасы “Әгерҗе муниципаль районы” муниципаль берәмлеге уставына таянып, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Белем бирү программаларын, шул исәптән электрон укыту һәм дистанцион белем бирү технологияләрен кулланып, тормышка ашыручы Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы мәгариф учреждениеләренә «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы муниципаль районы муниципаль гомуми белем бирү учреждениеләре укучыларының өстәмә социаль ярдәмгә мохтаҗ (яңа редакциядә) тукалнуын оештыру тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 21 декабрендәге 523 номерлы карары, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы муниципаль гомуми белем бирү учреждениеләре укучыларының өстәмә социаль ярдәмгә мохтаҗ (яңа редакциядә) туклануын оештыру тәртибе турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында» 2020 елның 20 мартындагы 99 номерлы карары, «Әгерҗе муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларында укучыларны

туклandыруны оештыру һәм туклану өчен түләүгә күчү турында» Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 11 мартындагы 85 номерлы карары нигезендә туклану бирелә торган Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы мәгариф учреждениеләре укучыларына Татарстан Республикасының гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү территориаль подсистемасы органнары һәм көчләре өчен югары әзерлек режимын кертү чорына коры паеклар бирүне оештырырга.

2. Укучыларга коры паеклар бирү тәртибе һәм аны оештыру мәгариф учреждениеләренең локаль актлары белән билгеләнә.

3. МКУ «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы мәгариф идарәсе»нә:

- Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы мәгариф учреждениеләрендә электрон белем һәм дистанцион белем бирү технологияләрен кулланып белем алучы укучылар исемлекләрен төзергә;

- Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы мәгариф учреждениеләрендә өйдә торып укучы укучылар исемлекләрен төзергә;

- Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы мәгариф учреждениеләрендә үз составында дүрт һәм аннан да күбрәк балигъ булмаган балалары булган гаиләләрдән, шулай ук янгыннан зыян күрүче гаиләләрдән укучылар исемлекләрен төзергә.

4. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Финанс-бюджет палатасында әлеге боерыкны гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны билгеләнгән тәртиптә финанслауны тәэмин итәргә:

4.1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы мәгариф учреждениеләрендә электрон белем һәм дистанцион белем технологияләрен кулланып белем алучы укучыларга, шулай ук Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы мәгариф учреждениеләрендә өйдә торып укучы укучыларга, 2020 елның май-апрель айлары өчен түбәндә күрсәтелгән күләмдә Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы бюджетыннан акча (уку чорында бер укучыга бер көнгә 7 сум 70 тиен республика субсидиясе) бүлеп бирергә:

- 1 нче сыйныф укучылары өчен - бер пакет коры паек өчен 215,60 сум;

- 2-8 сыйныфларда укучылар өчен - бер пакет коры паек өчен 254,10 сум;

- 9 сыйныфтан 11 сыйныфка кадәр укучылар өчен - бер пакет коры паек өчен 300,30 сум.

4.2. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы мәгариф учреждениеләрендә үз составында дүрт һәм аннан да күбрәк балигъ булмаган балалары булган гаиләләрдән, шулай ук янгында зыян күргән гаиләләрдән булган укучыларга Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы бюджетыннан 2020 елның май ае өчен түбәндәге күләмдә акча бүлеп бирергә:

- 1 нче сыйныф укучылары өчен – бер пакет коры паек өчен 162,90 сум.

- 2-8 сыйныфларда укучылар өчен – бер пакет коры паек өчен 199,10 сум.

- 9 сыйныфтан 11 сыйныфка кадәр укучылар өчен – бер пакет коры паек өчен 307,70 сум.

5. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында (https://www.agryz.tatarstan.ru) «Документлар» бүлегендә урнаштырырга.

6. Әлеге карар 2020 елның 21 маеннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

7. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары Р.Р. Гыйльметдиновага йөкләргә.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **А.С. Авдеев**